

Кылган гамәлләре, башкарган эшләре, яшәеше, ин моhиме, туган жиренә ихлас бирелгәнлеге белән райондашлар кvнелендә зур ихтирам hәм абруй казанып, бvгенгә кадәр тоткан кыйбласына тугрылык-лы булып калып, тыйнак кына фидакарь хезмәт юлы vтvче Наиль Халил улы Долотказин.
Наиль Долотказин 1958 елны Инсар районы Большие Поляны (Иса) авылынын Ибраhим кызы Сара белән Абдрахман улы Халил гаиләсендә беренче бала булып доньяга килә. Әнисе берникадәр чит шәhәрләрдә хезмәт иткәч, 45 ел колхозда торле эш башкарса, әтисе 48 ел буе электромонтерлык хезмәт юлы vтә. Балалык елларында Наиль Иса елгасы карын чистатып ясалган мәйданда хоккей уйный, урманында жәй коннәре жиләк жыя, Иса елгасы ташуында бата-чума чирпала белән балык тота... Жиденче класста ук комбайнер ярдәмчесе булып, иген сугу буенча алдынгылар булалар. Мәктәптә дә бик яхшы билгеләренә укый. Тырыш гаиләдә vскән Наиль Большие Поляны урта мәктәбен тәмамлап, Н.П.Огарев исемендәге университетнын физика бvлегенә укырга керә. Уку йортын тәмамлаганда армия сафларында хезмәт итеп, чыныгу алгач, зур хезмәт биографиясе башлана.      Бvген Наиль Хәлил улы Долотказин - Инсар районда танылган кеше. Үзенен хезмәт елларында район органнары ихтыяры белән ана Инсарда берничә житәкче вазифансын алмаштырырга туры килә. Һәм hәр жирдә характерынын ин яхшы сыйфатларын кvрсәтә - жаваплылык, намуслылык, компетентлык. Бу анын хезмәт биографиясенен беренче адымнарыннан ук кvренә. Комсомолнын район комитетында Наиль Халил улы Долотказинны хезмәттәшләре генә тvгел, ә ботен актив хормәт итә. Ул эшенен нигезләрен тирәнтен vзләштерә, моны комсомол оешмалары секретарьларыннан да таләп итә. Ул елларда район комсомолы эшенә ижади караш, инициатива белән аерылып торуы очраклы тvгел. Яшьләр терлекчелеккә актив эшкә баралар, ә игенчеләр ярышы массакvләм була. Комсомол - житештерvчеләр белән аралашу гына тvгел, ә hәр хужалыкта кече Ватан патриоты булырга сәләтле кешеләрнен нигезен формалаштыру да моhим. Бу эшне ул партиянен район комитетында, идеология бvлеген житәкләгәндә дә башкара.
Н.Х.Долотказинга язмыш мәгариф системасында эшләргә момкинлек бирә. Яшь, перспективалы белгечне Инсар сигезьеллык мәктәбе директоры итеп билгелиләр. Уку йортында яхшы vзгәрешләр башлана: педагогларга эш кызыклы була, аларнын ижаты, инициативасы очен кин кинлек бирелә. Директор vзенен педагогик идеяләрен практикада тикшерергә тели. Һәм шәhәр укытучылары арасында ул фикердәшләр дә таба. Ләкин тиздән аны башка эшкә чакыралар - Инсар районы башлыгы урынбасары, район молкәт белән идарә итv Комитеты рәисе. Яна вазифа турында шикләре булган анын. Ләкин мондый шартларда килгән тәкъдимне кире кагу кабул ителмәгән. Наиль Халил улы яна бурычларына бик актив керешә, яна гына оештырылган хезмәтнен эш формаларын hәм ысулларын ныклап тырышлыгы, белеме, әдәплелеге аркасында бик тиз vзләштерә. Район башлыгы аппаратында аны ин компетентлы белгеч, абруйлы житәкче дип санаганнар. Остәвенә, Наиль Халилович гадәти булмаган фикерләv, теләсә нинди,

хэтта катлаулы мэсьэлэне хэл итv сэлэте белэн аерылып тора. Һэм хэл итvе дэ шактый унышлы килеп чыга торган булган. Кыскасы, район масштабындагы “кризис” менеджеры була ул. Нэкъ менэ шушы сыйфат ана Инсар шэһэре башлыгы, Инсар район элемтэ узелы начальнигы вазифаларын башкару очен кирэк була. Аны районда хормэт итэлэр һэм кадерлилэр; бик жаваплы сорауларны vтэvне ышанып тапшыралар. Территориялэр белэн эшлэv буенча район администрациясе башлыгы, “Бердэм Россия” партиясенен Инсар жирле бvлеге житэк-челэренен берсе вазифаларын башкаручы да ул. Остэвенэ, сайлау кампа-ниялэре вакытында район сайлау штабын кvп тапкырлар житэклэгэн. Һэм барлык катлаулы участокларда vзен бары тик ин яхшы яктан гына кvрсэтте.
Кvп еллар Н.Х.Долотказин “Энергосервис” МУП-сын житэкли. Ул коммуналь хез-мэт житэкчелегенэ бик авыр вакытта килэ, коллективны берлэштерергэ һэм анын кочлэрен шэһэрне vстерv буенча бик житди бурычларны хэл итvгэ юнэлтергэ кирэк була. Вакыт кvрсэткэнчэ, ул бу эшне дэ унышлы башкара. Анын хезмэт еллары Инсар шэһэре һэм Инсар районы халкы кvз алдында уза. Наиль Халиловичны хормэт итэлэр, анын жирле актив арасында лаеклы абруе бар. Кvпьеллык намуслы эше очен ана “Мордовия Республикасынын атказанган жирле vзидарэ хезмэткэре” (звание “Заслуженный работник местного самоуправления Республики Мордовия”) дигэн мактаулы исем бирелэ, анын башка бик кvп бvлэклэре бар.
Наиль Долотказин булдыклы житэкче генэ тvгел, vрнэк гаилэ башлыгы да. Анын тылы да - ныклы һэм ышанычлы. Тормыш иптэше Рафик кызы Роза, гаилэ учагын гына саклаучы тvгел, э кинэшчесе дэ, фикердэше дэ булып тора. Долотказиннар ике ул - Ринат белэн Русланны тэрбиялэп vстерделэр. Икесе дэ ныклы белем алып, эшлэрендэ унышларга ирешеп килэлэр. Татар жанлы Наиль турында “душа коллектива” да дилэр, чонки ул булган жирдэ кояш та яктырак елмая. Жырлый башласа, рус, татар жырларын рэхэтлэрен, тэмен белеп, кvнелне тибрэндерерлек итеп жырлый - “Туган ягым минем Иса суы...”
Лаеклы ялга чыккач та тик тора белми ул. Наиль Халил улын ООО “Ткацкая фабрика “Лента” имени 8 марта” чакыралар. Бvген ул бу эшне дэ жиренэ житкереп башкарырга керешкэн - тиешле квалификация алып хезмэт итэ. Татарларда бер бик тэ матур эйтем яши - “урын кешене бизэми, э кеше эш урынын бизи”. Бу анын турында эйтелгэн тосле. Нэтижэдэ - тормышта ул жинел юллар эзлэмэде. Анын бурычы - кушкан урында эшлэv иде. Инсарлылар аны шунын очен дэ хормэт итэлэр.

**Салих КУТУЕВ**